**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Глава муниципального образования “Бирючевского сельского поселения”**

ул. Школьная, д.2 , д.Бирючевка, Азнакаевский район, 423307

Тел. (8-85592) 6-1881, факс (8-85592) 6-1881

E-mail: Bir.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**“Бирючевка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге БАШЛЫГЫ**

Мэктэп урамы, 2, Бирючевка авылы, Азна районы, 423307

Тел. (8-85592) 6-1881, факс (8-85592) 6-18

E-mail: Bir.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**Бирючевка авылы** **№108** **2 ноябрь 2020 ел**

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Бирючевка торак пунктында гражданнарныц үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. .Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Бирючевка авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2020 елның 12ноябрендә 17 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Котельная урамы 1 йорттан 12йортка кадәр.
2. . Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Бирючевка авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2020елның 13 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә:Мира урамы 1 йорттан12 йортка кадәр, Школьная урамы 1йорттан 4йортка кадәр,Молодежная урамы 1 йорттан 8 йортка кадэр,Центральная урамы 1 йорттан 35 йортка кадэр.

3. .Билгеләргә:
4. - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Бирючевка авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Башкарма комитеты;
5. - гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 12 ноябрь 2020 ел 17.00 сәг.тән 18.00 сәг.кадәр;
6. - гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 13ноябрь 2020 ел 17.00 сәг.тән 18.00 сәг.кадәр;
7. - гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Бирючевка авылы, Мэктэп ур. , 2йорт, Бирючевка авыл мәдәният йорты залы;
8. . Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:
9. - 2020 елның 02 нояреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Бирючевка авылы, Мэктэп урамы, 2 йорт
10. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Бирючевка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

1.Бирючевка авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча чаралар ( янгын гидрантларын, янгын техникасын карап тоту , (запас частьләр һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу)

2. Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар көне»нә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);

**3.** Бирючевка авыл җирлегенең урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампаларны, яктырткычларны сатып алу һәм алыштыру);

**4.** Халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү)

5. Юлларны карап тоту (юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру, Үзәк, Яшьләр, Тынычлык , Мәктәп, Котельный, Лесная урамнары буйлап урам исемнщре язылган табличкалар сатып алу);

6. Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (үлән чабу эшләре очен түләү(килешү буенча түләү, ягулык-майлау материаллары һәм триммер өчен запас частьләр сатып алу);

7. Карны механикалаштырылган җыю буенча хезмәтләр өчен (трактөрчыга), юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре өчен түләү, (ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу);

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык : В.В.Крашенинников